РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2025 Кукмара ш. № 658

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 04 декабрендәге 789 номерлы карары белән расланган Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәк-ярак товарларын Кукмара муниципаль районының Кукмара муниципаль районы үзәге Кукмара шәһәреннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына илтүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Кукмара муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 04 декабрендәге 789 номерлы карары белән расланган Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәк-ярак товарларын Кукмара муниципаль районының Кукмара муниципаль районы үзәге Кукмара шәһәреннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына илтүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Кукмара муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, (Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 27 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Субсидияләр биргәндә, аларны бирүнең субсидияләр бирү турындагы килешүгә кертелә торган мәҗбүри шарты булып, аларны алучыларның субсидияләр алучыларга һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булып торучы затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү максатларында, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә Кукмара муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләрне башкаруга ризалыгы тора.»;

1 нче кушымтаның 2.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.2. Субсидия алучыга һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булып торучы затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү максатларында, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә Кукмара муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләрне башкаруга ризалык бирә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**